**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет Сапеевского сельского поселения Азиакаевского муниципального района**

ул. Школьная, д. 53В, село Сапеево,
Азнакаевского муниципального района,
423326, Тел. 8 (85592) 44-2-40, факс 44-2-83
E-mail: Sap.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Сәпәй авылы җирлеге башкарма комитеты**

Мәктәп урамы, 53В, Сәпәй авылы
Азнакай муниципаль районы
423326, Тел. 8 (85592) 44-2-40, факс 44-2-83
E-mail: Sap.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

“18” октябрь 2022 ел №19

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законда каралган бурычларны үтәүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 26 гыйнварындагы 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2022 елның 14 июлендәге 266-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль законның 30 статьясындагы үндүртенче өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законда каралган бурычларны үтәүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 26 гыйнварындагы 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге башкарма комитетында шәхси мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләре» 1 нче кушымтаның 2 бүлегенең 1.3 пунктында «зыянны бәяләү» сүзләреннән соң «субъектларның шәхси белешмәләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле орган билгеләгән таләпләр нигезендә» сүзләрен өстәргә.

1.2. «Шәхси мәгълүматлар субъектларының яисә аларның вәкилләренең Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының

Сәпәй авыл җирлеге башкарма комитетында персональ белешмәләргә керү мөмкинлеген карау кагыйдәләре» 2 нче кушымтада:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әгәр федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны бирү һәм (яисә) оператор тарафыннан шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык алу мәҗбүри булса, оператор шәхси белешмәләр субъектына аның шәхси мәгълүматларын бирүдән баш тартуның юридик нәтиҗәләрен аңлатырга һәм (яисә) аларны эшкәртүгә ризалык бирергә тиеш.»;

б) 11 пунктта «30 (утыз) көн» сүзләрен «ун эш көне» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма оператор тарафыннан соратылган мәгълүматны бирү вакытын озайту сәбәпләрен күрсәтеп, мотивлаштырылган хәбәрнамәнең субъектлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле орган адресына җибәрелгәндә биш эш көненән артыграк булмаска тиеш.».

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http//aznakayevo.tatar.ru.//

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Ф.Г.Галиева